| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ ЛЕБЕДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЛЕБЕДИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**08.04.2026** с. Лебедино **№20**

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Лебедино авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 16.11.2018 ел, № 110 карарына үзгәреш кертү хакында (үзгәрешләр белән 22.03.2019ел, №120; 18.11.2019ел, №143; 05.08.2020ел, №161; 02.08.2024 ел, №68 карары)**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлегенә туры китереп, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебедино авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Лебедино авыл җирлеге Советының 16.11.2018 ел, № 110 «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына (үзгәрешләр белән 22.03.2019ел, №120; 18.11.2019ел, №143; 05.08.2020ел, №161; 02.08.2024 ел, №68 карары) түбәндәге үзгәреш кертергә:

2 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) 2,5 % карата:

һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артыграк булган салым салу объектларын, проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төзелеп бетмәгән объектлардан тыш;»

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Лебедино авыл җирлеге башлыгы, Совет Рәисе** **Ю.Г. Мингулова**